ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27 09 2024 г. № 1002

Гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының керемен еһәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы, гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен билгеләү методикасы һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакының минималь күләмен билгеләү методикасы нигезендә Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының керемен еһәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының максималь күләмен 48 100,49 сум итеп билгеләргә.

2. Гражданнар һәм алар белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары милкендәге мөлкәтнең яисә салым салынырга тиешле ялгыз яшәүче граждан хакын билгеләргә:

2.1. Ялгыз яшәүче кеше өчен – 2 686 428 сум;

2.2. Ике кешелек гаилә өчен – 5 372 856,00 сум;

2.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 8 059 284,00 сум;

2.4. Дүрт кешелек гаилә өчен – 10 745 712,00 сум;

2.5. Биш кешелек гаилә өчен – 13 432 140,00 сум;

2.6. Алты кешелек гаилә өчен – 16 118 568,00 сум;

2.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 18 804 996,00 сум;

2.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 21 491 424 сум.

3. «Гражданнарның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзаларының керемен еһәм алар белән бергә салым салынырга тиешле мөлкәтнең хакының

максималь күләмен билгеләү турында» 2022 елның 27 маендагы 136 номерлы Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Ф. Булатов